СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга | №37 (7210) | 30 март, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

РСФСР халык депутатлары Съездында



МӘСКӘҮ (ТАСС). Кремльнең Зур сараенда 29 мартта РСФСР халык депутатларының III (чираттан тыш) съезды эшен дәвам итте. Съездда катнашучылар көн тәртибе проектын тикшерүгә кабат әйләнеп кайттылар. Бу проектка өстәмәләр алдагы көнне депутатлар группалары һәм партияләре вәкилләре катнашында консультатив тәртиптә каралган иде инде.

28 мартта Съезд көн уртасына кадәр генә эшләде. Депутатлар РСФСР Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары Р. И. Хасбулатовның депутатлар тапшыруы буенча съезд утырышының башында кабул ителгән карар пунктларын СССР Президенты игътибарына җиткерүе турындагы информациясен тыңладылар. Чыгыш ясаучының сүзләре буенча Президент тәртипсезлекләрне кисәтү өчен кертелгән гаскәрләрнең икенче көнне чыгарылачагын вәгъдә иткән.

Бу белдерү кискен дискуссияләр кузгатты. Кайбер депутатларның тынычшартларда форум эшен дәвам итүгә чакыруларына карамастан, күпчелек ораторлар аның барышын туктатуны таләп иттеләр. Дискуссия барышында күп тәкъдимнәр яңгырады. Съезд күпчелек тавыш белән 29 мартның иртәнге 10 сәгатенә кадәр тәнәфес игълан итте.

Җомга көнне иртән председательлек итүче Р. И. Хасбулатов СССР Президентының вәгъдәсен үтәвен, Мәскәү үзәгендә гаскәрләр юклыгын, ә Мәскәү милициясенең шәһәрдә тәртип саклау буенча үз бурычын башкаруын хәбәр итте.

Аннан соң съездда алдагы көнне килешү комиссиясе өстәмә рәвештә эшкәрткән көн тәртибе проекты буенча дискуссия җәелдерелде.

Съезд эшен дәвам итә.

Мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмәдә чөгендер игү осталары аз түгел. Минзифа Галиева —шуларның берсе. Гомер буе җәен чөгендер игүдә, кышын төрле эштә булды ул. Сыерын да сауды, саламын да тапатты. Шәхси йортында да төп эш Минзифа апа җилкәсендә булды. Сабыр һәм эшчән хатын-кыз тормышның бөтен сынауларын да кичеп, күңел көрлеген саклый алды. Хәзер дә Минзифа апа хезмәттән аерылмый. Ул тегермән тарттыра.

Рәсемдә: мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә эшчесе М. Галиева.

Футболчылар белән очрашу

27 мартта халык депутатларының район Советы рәисе, КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов «Факел» футбол командасы уенчылары белән очрашты.

Очрашу барышында Хәлил Хәмзиевич команданың профессиональ нигездә оештырылуын, аның быел ТССР чемпионатында беренче группада һәм РСФСР буенча Идел буе зонасында ярышларда катнашуын билгеләп үтте, якташларыбыз алдына конкрет бурычлар куйды.

Сөйләшү барышында команданың тренеры В. И. Федотов команданың Новороссийск шәһәрендә җыенда күнегүләрне ничек үтүе, уенчыларның физик чыныктыруга игътибарны көчәйтү, икенче кабат шул ук шәһәрдә җыелу барышында алда торган бурычлар турында сөйләде.

Сөйләшү барышында команда уенчылары Н. Абдуллин, П. Антонов «Факел»ны кызыксындырган проблемаларны кузгаттылар. Бер үк вакытта шәһәр стадионын реконструкцияләү буенча алда торган бурычлар да тикшерелде. Очрашуда катнашучылар «Факел» командасының тамашачыларны җәлеп итәрлек уйнавын, сезонда уңышлы чыгыш ясавын теләделәр.

Җыелыш үтте

27 мартта «40 лет Победы» колхозы колхозчыларының гомуми җыелышы булып үтте. Җыелыш башка эшкә күчүе сәбәпле Р. Х. Хәсәновны колхоз рәисе вазифасыннан азат итте. Рәис итеп «Путь к коммунизму» колхозында баш зоотехник булып эшләүче Шәрифҗан Шәфикович Төхвәтуллин сайланды.

Җыелыш эшендә КПСС райкомының икенче секретаре Ә. В. Мөлеков катнашты һәм чыгыш ясады.

Ш. Ш. Төхвәтуллин

Шәрифҗан Шәфикович Төхвәтуллин 1950 елда Савин авылында туган. Хезмәт юлын Буа ветеринария техникумын тәмамлагач 1969 елда «Путь к коммунизму» колхозында ветфельдшер булып башлый. Совет Армиясеннән кайтканнан соң Казан Дәүләт ветеринария институтын тәмамлый һәм кабат шул ук хуҗалыкка ветеринария врачы булып кайта. 1979 нчы елдан шул ук колхозда баш зоотехник булып эшли.

Беренче кварталны — уңыш белән

Безнең комбинат беренче кварталны шактый гына уңышлар белән тәгәлләде. План буенча бер миллион 200 мең сумлык продукция реализацияләнергә тиеш булса, 27 нче мартка сатылган продукциянең күләме бер миллион 210 сум тәшкил итте. Узган елның беренче кварталында продукция быелгыдан 300 мең сумга кимрәк сатылган иде, үсеш динамикасы 132,4 процентка җитте.

Комбинат планын бигрәк тә камыр әйберләре, шикәрле кондитер әйберләре җитештерү һәм суган киптерү цехлары продукцияләре исәбенә арттырып үтәде. Кондитер әйберләре чыгару **буенча үсеш динамикасы** 123,8 процент тәшкил итә. Нина Андреева, Валентина Кузнецова, Ангелина Бикинеева, Гөлсинә Төхфәтуллина продукция җитештерүдә зур өлеш кертәләр.

Шикәрле кондитер әйберләре чыгаруда беренче квартал планын 300 процентка үтәдек. Быел вак конфетлар ясау нәтиҗәсендә квартал планын узган елдагыдан 19,2 тапкырга арттырдык.

Суган киптерү цехы коллективы да өч айны нәтиҗәле тәгәлләде. Үсеш динамикасын 192,9 процентка җиткерде. Бирелә Тәнзилә Алексеева, Наилә Гәрәева, Надежда Яругина тырыш хезмәт куялар.

Азык комбинаты уңышлары турында сөйләгәндә, ипи пешерүчеләр хакында да әйтеп үтмичә мөмкин түгел. Бу өлкәдә үсеш динамикасы 131,2 процентка җитте. Планнан бигрәк, ипинең сыйфатлы һәм тәмле булуы нык куандыра. «Тәрнәс» совхозы пекарнясын гына алыйк. Аларның кабарып пешкән йомшак икмәкләре Нурлат халкына да таныш. Бу продукция Элфия Алиева, Валентина Янилина, Людмила Петрова һәм башкаларның уңган куллары, тырышлыгы нәтиҗәсендә барлыкка килә.

В. ИБРАҺИМОВ,
азык комбинаты директоры.

Сессия чакырыла

1991 елның 4 апрелендә XXI чакырылыш халык депутатларының район Советының дүртенче сессиясе КПСС райкомының конференцзалында чакырыла. Сессиянең көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләрне кертү күздә тотыла:

1. Халык депутатларының район Советы башкарма комитетының 1990 елдагы эше турында отчет.

2. Халык депутатларының район Советының культура, халык мәгарифе һәм яшьләр эше буенча даими комиссиясе эше турында отчет.

3. 1990 нчы елда үткән сессияләрдә халык депутатларының район Советы депутатлары керткән тәнкыйть фикерләре һәм тәкъдимнәренең үтәлеше барышы турында информация.

Игътибар: „көлү көне“

Быел ул шәһәрдә 31 мартта булачак. Ул көнне иртәнге 9 сәгатьтә шәһәрнең үзәк мәйданына ашыгыгыз. Сезне анда һәртөрле күңел ачулар, көч сынашулар һәм күңелле мәҗаралар көтә. Бу көнне сез спорт ярышларында катнаша, күңелле концерт программасын карый аласыз, кино сөючеләрне шәһәр кинотеатрында кинокомедия һәм мультфильмнар көтә. Елмаерга, көләргә яраткан, юморны аңлаган, зирәклеккә соклана белгән һәркем бу көнне рәхәтләнеп ял итәр, яхшы кәеф, күтәренке рух алыр. Үзенең активлыгы белән бәйрәмне тагы да җанлырак итәргә теләүчеләрне һәртөрле призлар көтә. Кайнар чәй, сый-нигъмәтләрнең төрледән-төрлесе булачак.

«Көлке көне»нә рәхим итегез!

Ашлаган кыр аш бирә

Ашаткан малда, ашлаган кырда бәрәкәт бар, диләр. Моны безнең колхоз хезмәтчәннәре дә исләреннән чыгармый. Әнә шуңа да җиргә органик ашламалар кертү кышның салкын көннәрендә дә туктатылмады, хәзер дә дәвам итә.

Басулар белән черемә өемнәре арасында хәрәкәт тукталмасын өчен Расыйх Сәгыйров зур тырышлык куя. Төяп торуда ул. Ә борчак, бодай һәм башка культуралар астына черемә чыгаруда Вахит Сабиров, Тәбрис Садыйков, Әхәт Сөнгатуллин эшли. Алар үзләренең көнлек нормаларын үтәп килә. Бүгенге көндә хуҗалык басуларына 7640 тонна органик ашлама чыгарылды инде.

И. ЗӘЙНУЛЛИН.
«Чирмешән» колхозы.

ӘЗЕРЛЕК ӘЙБӘТ

«Комбайн» колхозы. Техниканы язгы чәчүгә әзерләү бирләдә зур оешканлык белән барды. Бүгенге көндә язгы эштә катнашачак техника тулысынча диярлек әзерлек сызыгында. Бу—иң әлек 1 нче һәм 2 нче бригадаларда бригадирларның техника буенча ярдәмчеләре Рафик Сафин һәм Фаиз Сафиуллинның эшне дөрес оештыруы нәтиҗәсе, 1 бригадада слесарьлар Юрий һәм Александр Похачев, Илсөяр Хәйдәров, II бригада слесарьлары Әсгать Әхмәтов, Сәлим Нәбиуллин, Фәүдәт Сафин, Марс Әхмәтов, әтиле-уллы Хәсән һәм Ранас Мотаһировлар авыл хуҗалыгы техникасын төзәтүдә фидакарь хезмәт куйдылар. Мастерской эшчеләре бакырчы Әсәви Әхмәдиев, тимерчеләр Фәйзерахман Сәмәрханов, Гали Мифтахов, токарь Рафик Хәлимовның тырыш хезмәте дә моңа бик булышты.

Хәзерге көндә техниканы кадрлар белән тәэмин итү бара. Быел хуҗалык язгы чәчүне 2 сменада оештырырга ниятли, шуңа да кадрлар туплау белән бергә төнге сменада эшләү өчен җайланмалар да көйләнә. И. НӘБИУЛЛИН.

Үзебезнең хезмәтебезгә бәйле

Икмәк булса, җыры да була, диләр халыкта. Хак сүзләр болар, чөнки икмәк игенче һәм эшче өчен дә бердәй кирәк.

Үткән ел уңышны җыюда районыбыз хезмәт ияләре—авыл һәм шәһәр халкы да кулга-кул тотынып эшләделәр. Күмәк тырышлык белән, мәсәлән, 1500 гектар мәйданда шикәр чөгендере кулдан алынды. Районда, күп күршеләребездән аермалы буларак, үстерелгән уңыш тулысынча җыелды. Моңа алда әйтелгәнчә, шәһәр эшчеләренең дә хезмәте күп керде.

Инде чираттагы, 1991 ел язы җитте. Бу көннәрдә авыл хезмәтчелләре чәчү алдыннан була торган киеренкелекне тоеп, куанычлы һәм борчулы мәшәкатьләр белән яшиләр. Шулай булмыйча мөмкин түгел, чөнки алда аларны киеренке хезмәт, көзен башкарырга мөмкин булмаганга үтәлми калган күп эшләр дә көтә бит. Шуларны исәпкә алып СССР Министрлар кабинеты 1991 елның 1 мартында хезмәткә сәләтле халыкны һәм йөк автомобильләрен авыл хуҗалыгы эшләренә тарту тәртибе һәм шартлары турында махсус карар кабул итте. Газета корреспонденты шушы уңайдан халык депутатларының агропромышленность комплексы, промышленность, төзелеш, транспорт һәм элемтә буенча даими комиссиясе рәисе, КПСС райкомының икенче секретаре Ә. В. Мөлеков белән очрашты һәм әлеге карарга бәйле кайбер сорауларга җавап бирүне үтенде.

КОРР: Әхмәт Вәлиәхмәтович, мондый карарга карата үз фикерегезне белдерсәгез иде.

МӨЛЕКОВ. Аны мин тулысынча нигезле саныйм. Юкса, ничек килеп чыга: игенче теләсә ничек үстерсен һәм бирсен. Үткән ел көз яңгырлы килде, күп урында уңышны җыюга «бир» дигән принциптан чыгып кына карадылар. Моның нәтиҗәсе мәгълүм: күпме икмәк, шикәр чөгендере һәм башка культуралар уңышы кар астында калды. Үткән ел ил күләмендә моңарчы күрелмәгән күләмдә уңыш үстереп тә, бүген азык-төлеккә кытлык кичерү шуның нәтиҗәсе түгелмени!

КОРР. Безнең районда үткән ел уңышны җыюда шәһәр хезмәт ияләре актив катнашты.

МӨЛЕКОВ. Уңышны тулы җыеп алганбыз икән, монда норлатлыларның да хаклы өлеше бар. Һәм мәсьәләнең икенче ягын да истән чыгарырга ярамый: авыл шәһәргә ярдәм итми мени?! Ел саен берничә ярминкә оештырыла, анда шәһәр халкына күпме азык-төлек сатыла. Шуңы һәр коллектив аңлап эш иткәндә—авылда һәм шәһәрдә дә табыннар тулырак, халыкның күңеле көр булыр.

КОРР: Әхмәт Вәлиәхмәтович, кабул ителгән карарда авылга нинди ярдәм күздә тотыла?

МӨЛЕКОВ Карарда авыл хуҗалыгы эшләренең иң киеренке чорында шәһәрләрнең һәм эшчеләр поселокларының промышленность предприятиеләре, оешмалар һәм учреждениеләр эшчеләре, профтех училище курсантлары һәм башкалар авылга хезмәткә җибәрелергә мөмкин. Моннан тыш, авылга кыр эшләре башкару өчен яраклы техника, автотранспорт җибәрү күздә тотыла. Кайбер хуҗалыкларда механизатор кадрларга кытлык сизелә. Андый хуҗалыкларга квалификацияле белгечләр —әйтик механизаторлар җибәрү зур ярдәм булачак.

КОРР. Мондый очракта элек аерым тармак предприятиеләрен, мәсәлән, тимер юлчыларга ташлама ясала иде. Хәзер ничек?

МӨЛЕКОВ. Алар хәзер дә саклана. Тимер юлчыларның йөкләрне ташучы, хәрәкәт куркынычсызлыгын тәэмин итү службалары работниклары мондый эшләргә тартылмыйлар. СССР Госснабы, милиция, сәүдә учреждениеләре, шулай ук предприятиеләрдә һәм оешмаларда технологик процессларны тәэмин итүче автомобильләр мөһим кыр эшләре кампаниясе чорында да авылга ярдәмгә тартылмый.

КОРР. Авыл хуҗалыгында хезмәттә катнашучыларны түләү тәртибе кызыксындыра, әлбәттә.

МӨЛЕКОВ. 1991 елның 1 апреленә кадәр колхозлар, совхозлар һәм агропромышленность комплексының башка предприятиеләре белән промышленность, транспорт предприятиеләре һәм оешмалары арасында авылга кызу эш өсте чорында кешеләр һәм техника белән ярдәм күрсәтү буенча килешүләр төзелергә тиеш. Килешүләрдә работникларны кабул итү, тиешенчә туклану оештыру, хезмәткә түләү тәртибе, шартлары һәм башкалар каралган булу шарт. Бер ук вакытта килешүләрдә авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашучы предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга үстерелгән уңышның яисә алынган продукциянең бер өлешен дәүләт сатып алу, яисә үзара килешү бәяләре белән бүлеп бирергә мөмкин. Натуралата алынган продукция хезмәт коллективларында җәмәгать туклануын яхшырту яисә работникларга бүлеп сату өчен дә файдаланырга рөхсәт ителә.

Йомгаклап шуны да әйтәсе килә, авылда язгы чорда башкарасы эш күләме алдагы еллардагыдан күпкә артык. Шуны белеп авыл хезмәтчелләре ныклап хәзерләнделәр, барлык төр техника сафка бастырылды, орлык тунланды, оештыру чаралары күрелде. Шулай да кырга чыккач эшне оешкан төстә алып бару, оптималь срокларда башкару, уңышка ышанычлы нигез салу өчен авыл һәм шәһәрдән ярдәмгә килгән хезмәтчелләргә дә икеләтелгән энергия белән эшләргә туры киләчәк. Һәм мин, сүз уңаеннан, районыбыз коммунистларын, барлык игенчеләрне, шәһәр хезмәт ияләрен икмәк язмышы өчен фидакарь көрәшкә актив кушылырга чакырам. Чөнки иртәгәсе көндә тормыш-көнкүрешебез, киләчәгебез бүгенге хезмәтебезгә бәйле. Икмәк игүгә кагылышы булган һәркем шуны исендә нык тотсын иде.

ГАЗЕТАДА БАСЫЛМАСА ДА

Сусыз да, җылысыз да

Редакциягә Куйбышев урамының 94, 96 нчы йортларында яшәүчеләрдән бербер артлы ике хат килгән иде. Алар аның берсендә: «Суга тилмерәбез. Җәй көннәрендә бакчага сибәләр, шуңа юк дип аңлаталар иде. Ә хәзер ничек аңлаталар икән. Суны Южный, Красноармийская урамнарыннан ташыйбыз», —дип язсалар, икенчесендә: «Өйләребез ягылмый, түзәрлегебез калмады. Ике йортта егерме ганлә яши, балалар белән «больничный» башыбыз чыкканы юк. Өйләрдә һәрвакыт төрле температура, ял көннәрендә бөтенләй ягылмый диярлек»,—дип зарларын сөйлиләр һәм ярдәм итүне сорыйлар.

Без хатны шәһәр Советы рәисе М. М. Фәрраховка юллаган идек. Җавапны бары тик беренче хатка гына алдык. Биредә түбәндәгеләр хәбәр ителә: «Октябрь район Советы башкарма комитетының күнтармаклы производство предприятиесе тарафыннан Куйбышев урамы буенча су белән тәэмин итүне яхшырту максатында ремонт эшләре үткәрелде. Хәзерге вакытта бу урамны су белән тәэмин итү нормальләште».

Редакция җылылыкка кагылышлы хатка да җавап килүен көтеп кала.

ГАФУ ҮТЕНҮ БУЛМАС

«Газетагызның 1991 нче елның 17 январь санында «Сәүдә кагыйдәләре бозыла» исемле мәкаләне газетада төзәтеп бирүегезне үтенәм. Биредә минем исемемә, ОБХСС тикшерүе нәтиҗәләре буенча аңа җинаять эше ачылды, дигән яла ягыла, бу чеп-чи ялган. Гаризага район эчке эшләр бүлегеннән алган белешмәне беркетәм. Газетада ышандырырлык итеп төзәтеп бирүегезне үтенәм, шулай булмаса халык судына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булам»,—дип яза Н. М. Нуриева.

Ә менә редакциягә Югары Норлат авылы пенсионер-ветераннарыннан килгән икенче хат.

«Хөрмәтле, редакция! Безгә, коллективлашу, сугыш елларында көнен дә, төнен дә эштә уздыручыларга, иң кирәкле товар сатып алу мөмкинлеге юк, хәтта чиратта торсак та. Яшь чакта киенергә кием юк иде. Моның өчен вакыты да, акчасы да булмады. Хәер, без кибеткә йөрми дә идек. Ә менә хәзер, чиратын житкәч,безне үзеннекеләргә дә, читләргә дә бүлү кирәк идеме икән. Нишләмәк кирәк, бары да кибетченең күршесе була алмый бит. Элек товар терлекчеләргә генә кайтты дияләр иде, аннары ила рәдәге бухгалтерларга бирә башладылар, алга таба укытучылар... Күршеләр Мәрьям Әхмәтсафина, Роза Мортазина, Зәйнәпкә һәрчак барысы да бар, яисә «калдырган», я булмаса үзенең кызын җибәрә. Хәер, дәфтәр битенә барысын да язып булмый.Ә ир-ат күлмәкләре, аяк киемнәре кайтса, укытучы Ранас Нотфуллинга бирергә ярый, колхозчы Әнәс Мусинга ярамый, чөнки Югары Норлат кибете сатучысы Нурания Нуриевага аның бернинди дә файдасы тими. Аның сатып алучыларга карата шундый тупас карашы кайчан бетәр. Без пенсионерлар, нинди дә булса чаралар күрелүен көтәбез. Аның туганнары һәм якыннары кебек үк безнең дә матур оеклар киеп йөрисе, оныкларыбызны колготкалар белән куандырасыбыз килә. Тик безгә аларны Нурания күрсәтми дә. Алга таба да чаралар күрелмәсә башка юлын табарбыз.

Пенсионерлар: Мусина, Әхмәтсафина, Мөхәммәтова, тагын 7 имза».

Бу хат ОБХССка юлланды. Озакламый редакциягә җавап та килде. Анда күренгәнчә, хат килгәнче берничә көн алдан бу кибеткә ОБХСС тарафыннан тикшерү үткәрелгән. Шулай ук, факт буенча җинаять эше ачылды, тикшерү бара, дип хәбәр ителгән иде. Анда язылган ветераннар хатыннан күчермә белән бергә «Дуслык» газетасында нәкъ шул җавап басылды да.

Хаксызга рәнҗетүнең никадәр авырлыгын аңлап, бу очрак белән якыннан танышырга, авылга барып, халык белән сөйләшергә карар кылдык. Әйе, Нурания яклаучылар бар авылда. Алар—авыл Советы рәисе В. Х. Шәйхетдинов, колхозның профком рәисе Р. Х. Шәйхетдинов һәм тагын кайбер иптәшләр. Әмма безнең колхозчылар фикерен беләсе килде. Шуңа карамастан, алар дәшмәделәр. Хәер, аларны аңлавы кыен түгел, шунда яшиселәре, сатучының рәхим-шәфкатен яисә кирәсен көтәселәре бар бит әле. Тик шулай да бер колхозчының ярымшаярту тонында булса да әйткән сүзләре, күп нәрсәгә күзне ачты.

—Яхшы безнең сатучылар, тик менә товар китергәч, нигәдер һәрвакыт кибетне санитар сәгатькә ябып куялар. Ә ник аны бикләргә, безнең алда бушатсыннар иде.

Нигезле кисәтү шулай бит, мондый очракта беркем дә товар бушатышудан баш тартмас иде. Ләкин...! Ул чакта бит нәрсәнең күпме кайтканын халык беләчәк. Ә алар моны теләми.

Билгеле, болар барысы **да безнең фараз итү генә,** ә фактлар. Фактлар менә нәрсә сөйлиләр: кибеттә тикшерүдән күренгәнчә, сатучылар түбәндәге товарларны яшергән булалар: «Весна» магнитофоны, ир-атлар ярымпальтосы һәм

Хат эзеннән

куртка, өч пар итек, ир-атлар һәм хатын-кызлар туфлилары, ике сортта одеколон, шул исәптән ике декоратив келәм һәм сигез метр тар келәмне Нурания Мингәрәевна үзе калдырган.

«Шулай итеп, Нуриева РСФСРның җинаятьләр кодексының 156—3 нче статьясы, 1 нче частендә каралган буенча эш урыныннан файдаланып җинаять кыла.

...Тикшерү барышында үз гаебен таныды һәм дөрес мәгълүматлар бирде.

...Нуриева кылган җинаятьнең җәмгыятькә зур куркыныч янамавын исәпкә алып, Нуриеваны җәмәгатьчелек йогынтысы астында төзәтү һәм яңача тәрбияләү мөмкин дип уйларга нигез бар».

Шулай булгач Нуриеваның язмышын иптәшләр суды хәл итәчәк.

Ә без, Нурания Мингәрәевна, үзебезне гаепле итеп сизмәгәнгә күрә, сезнең алда гафу үтенмибез, ә сез?

Г. ХӘЛИУЛЛИНА.

МӘСКӘҮ ӨЛКӘСЕ. Ир-ле-хатынлы Тамара Николаевна һәм Василий Николаевич Брусовлар үзләренең крестьян хуҗалыгы булдыру турындагы күптәнге хыялларын тормышка ашырдылар. Элекке Мәскәү кешеләре арендага 25 елга «Щапово» агрофирмасыннан 6 гектар җир алдылар. Йорт салалар, ферма өчен агач хәзерлиләр. Брусовларның Зааненский токымлы нәсел кәҗәләре, Альфа-Лаваль токымлы сарыклары, кошлары, ике сыер, ике ат һәм шулай ук 2 йөк машинасы, 2 тракторлары бар.

Брусовлар профессионаллар. Хатыны авыл хуҗалыгы академиясен, ә ире ат асраучылык буенча институт тәмамлаган. Алар берничә ел АКШта совет илчелегендә эшлиләр, анда Василий Николаевич авыл хуҗалыгы буенча консультант була, фермерлар тормышын өйрәнә һәм хәзер Америкада күргәннәрен үзендә тормышка ашырырга уйлый.

Озакламый ярдәмгә гаиләсе белән улы кайтачак, ә хәзергә ширкәттә катнашучылар, аерым алганда Мәскәү базарында сөт продуктлары—эремчек һәм сыр сатуда ярдәм итәләр.

Актуаль интервью

Базарга—„тыл“ны ныгытып

Соңгы көннәрдә кибетләр тирәсендәге мәхшәргә кушылмаган кеше сирәктер. Менә хәзер генә товар кайтудан түгел бу җанлылык. Базар экономикасына ничек булса да үз экономикасын ныгытып керергә ниятли халык.

«Норлатнефть» НГДУсы эшчеләрне тәэмин итү бүлеге начальнигы урынбасары В. Н. ХУҖИНА белән шулар хакында сөйләшәбез.

—Вәсилә Нургаяновна, әлеге «кибет» синдромы сезнең ОРС ажиотажы мисалында да чагыладыр бит?

—Картинаны ачыклау өчен берничә сан китерү дә җитә, минемчә. Элек безнең система кибетләрендә сатылмый яткан товар-залеж 70 меңнән дә ким булмый иде. Анда аяк киемнәре, мәктәп формалары, цинк, пластмасс чиләкләр, кастрюль кебек товарлар була иде. Исегез китсен—хәзер ул бездә юк дәрәҗәсендә! Соңгы март аенда гына да 100 мең сумлык яткан товар сатылды. 3—4 ел яткан мәктәп формаларын 5 әрне алалар, иләк-чиләк, мунчала, себеркегә хәтле калмады. 1 нче промышленность товарлары кибете (мөдире В. В. Сметанина) көнгә 3700, күп булса 5 мең сум товар әйләнеше бирә иде. Хәзер кызлар 20—23 меңлек сату итәләр. Күрәсез: аерма бик зур!

—Ә бу сезнең өчен яхшымы, яманмы? Ни дисәгез дә сез арендада эшлисез бит әле?

—Бер яктан яхшы. Яткан товарлардан арындык, дөресен әйтергә кирәк, алар сыйфатлы, кирәкле булганнан сатылмый ятмаганнар бит инде. Ә арендага килсәк—без кыенлык кичерергә тиеш түгелбез. Эзләнергә, йөрергә туры киләчәк, әлбәттә.

Әле менә товарларны күпләп сату ярминкәләре графигы белән танышып утырабыз. Май аенда Уфа, Ульяновск шәһәрләренә, июньдә—Махачкала, августта Куйбышев шәһәрләренә барырга уйлыйбыз. Анда үзебез өчен файдалы килешүләр төзергә ниятлибез. «Норлатнефть» НГДУсы каршында «Пластик» кооперативы белән килешүебез бар. Яшелчә, җиләк-җимешне читтән әзерләргә уйлыйбыз. Болар безгә кибет киштәләрен тутырырга, сатып алучылар ихтыяҗын канәгатьләндерергә булышыр дип уйлыйбыз.

—Ә бәлки сез, кайберәүләр уйлаганча, үтемле товарларны бәя артканчы базада шыплап тотырып торасыздыр?

—Сез нәрсә! Кайткан товарны без комиссия каравына куеп, исемлек белән яки турыдан-туры сатуга чыгарабыз. Базада безнең ихтыяр белән тоткарланган товар юк. Бәяләре әлегәчә булмаганлыктан сатуга чыгарылмаган келәм әйберләре, консервларны исәпкә алмаганда, әлбәттә. Алар дөрестән дә үзләренең «йолдыз» сәгатьләрен көтәләр.

—Инде сезнең хатын-кыз буларак сүзегезне ишетәсебез килә. Бу товар синдромы, базар экономикасына кергәч, халыкка чынлап та җиңеллек китерерме, сезнеңчә?

—Беләсезме, мин моңа шикләнәм. Әлбәттә, яңа бәяләр, бигрәк тә балалар әйберләренә куелган бәяләр, күпләрне өркетерлек. Әмма икенче яктан, бөтен гомергә җитәрлек запас җыю да мөмкин түгел. Безнең ярлылык, экономикабызның тотрыксызлыгы халыкны шулай «запаслы» тотарга мәҗбүр итә инде. Шулай халыкның үз-үзен тынычландырырга теләведер, үзенчә. Соңрак 2—3 ай үткәч, аларны елмаеп искә алырга гына булсын иде дә бит...

—Әйе, шулай була күрсен! Әлегә елмаерга теләүчеләр сирәк шул әле...

Әңгәмәне С. ХӘЙРУЛЛИНА алып барды.

Мактаулы һөнәр иясе

Һөнәреңне тел тидерә алмаслык дәрәҗәдә белү, бөтен күңелең белән эшләү үзе ярты бәхет бит ул. Мансур Әбуталипович Борһанов нәкъ шундый кешеләрнең берсе. Алдан Норлат разведка бораулавы идарәсендә, соңрак технологик транспорт идарәсендә яраткан һөнәре бульдозер һәм трактор краны машинисты булып эшли. Кая гына эшләсә дә, җиренә җиткереп башкара, шуның белән яшьрәк эшчеләргә дә үрнәк булып тора.

Шулар белән бергә Мансур Әбуталипович яхшы гаилә башлыгы да әле. Гаиләдәге җылы мөнәсәбәт, яраткан эш булганда тагын нәрсә кирәк кешегә.

Рәсемдә: УТТның трактор краны машинисты М. Ә. Борһанов.

ЯЗ ШАЯРТУЛАРЫ

Өчнең берсен сайла

Кызлар һәм егетләр турында сүз бармый, әлбәттә. Бу сүзне Советская урамы буйлап йөрүче пассажирлар әйтә. Хикмәт шунда ки, бу урамнан шәһәр эчендәге автобуслар бөҗра системасы буенча йөри. Пассажир өчен үзе бик тә кулай буласы: ике яктан килүчесенә утырсаң да шәһәр үзәгенә барып чыгасың. Тик бер ләкин бар. Ул түбәндәгедән гыйбарәт: тукталыш будкалары уртак түгел, берсеннән берсе шактый еракта. Автобуслар хәрәкәтенең атасы-анасы, ягъни тәртибе-чираты юк, кайчан кайсы килгәсен һич белә алмыйсың. Хәрәкәт расписаниесе эленми, эленсә дә сакланмый, шуңа күрә якындагы тукталышка чыгып басасың. Автобусы, башы муен астына килгере, сиңа каршы яктан килеп чыга. Аны күрсәң дә каршы яктагы тукталышка барып өлгерә алмыйсың—автобус китеп бара. Син юлның икенче яктагы тукталышына чыксаң, үч иткәндәй, ул янә көтмәгән юнәлештән килү сәбәпле пассажирлар өченчесен сайлыйлар—автобуска ышанып, көтеп тормыйча җәяү генә китеп баралар.

Заманга ияреп

Заманында концентрация дигән нәрсәне, ягъни бер төр әйберне бер җиргә туплау дигәнне безнең колакларга нык тукыдылар. Шуннан канга сеңеп калган, ахрысы, хәзер талонга тиешле азык-төлекне дә шулай бер сәүдә ноктасына туплый башлаганнар. Бер төр продукт кирәк булса, шәһәрнең бер башына, икенчесе өчен икенче, өченчесе өчен өченче почмакка барырга туры килә. Замана артыннан йөгерергә көчең генә җитсен.

Туплады Р. АЙЗАТУЛЛИН.

Табышмакларга җаваплар

—Шәһәрнең үзәк почта киоскында сез сатып ала алмаган әйбер нәрсә ул?

—Татарча газеталар.

x x x

«Дуслык»ның 34 (23 март) санында табышмак-баш-ваткычны укып баш ватучылар байтак булгандыр. Аның да җавабын бүген бирергә булдык. Карт килеп байның улларына: «Атларыгызны алмаштырып чабыгыз», дигән. Малайлар атларны алга уздыру өчен куган да куган: чөнки байлык арттан килүче атка эләгә. Һәркайсы үз атын артта калдыру өчен тырышкан.

Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.

Борчылып язган хат

Чирмешәнне коткарырга

Кизләү авылы янында Чирмешән елгасының аяныч хәлен күрү мине редакциягә язарга этәрде. Үткән атнада анда балык тотарга барган идем. Әмма кая анда балык тоту? Чирмешән өсте тирес өемнәре белән чуп-чуар. Бу урыннарда (Кизләү тирәсендә) җәй айларында да булгалаганым бар. Әйтергә кирәк, биредәге кебек шапшак авылны тирә-юньдә күргәнем юк. Урыс, чуваш авыллары кырт итеп тора, ә бу мәчетле, димәк, үзе чисталык, пөхтәлеккә өнди торган авыл дуңгыз абзарын хәтерләтә. Ул гына җитмәгән бөтен пычракларын Чирмешәнгә түгәләр, Фермалары белән бергә бер-рәттән авыл халкы да.

Чирмешәннең чисталыгы авыл Советына кирәкме, юкмы, анысын белмим. Әмма киләчәгебез өчен бу бик аяныч, куркыныч күренеш. Әгәр дә бозлар эрегәнче тиресне алдыру җае табылмаса, аннары соң булачак! Чирмешәнне күз алдында юкка чыгарабыз.

Ә. ИЛЬЯСОВ.

Норлат шәһәре.

Көнбагыш алыгыз!

(Юмореска)

Башка хәсрәт төште әле. Теге 60 сум компенсацияне ничекләр туздырыйм икән? Нәрсә алсам, базар экономикасына чырай да сытмый килеп керермен икән? 30 сумына көнбагыш алам. Күршебез Мәгүзә әби кичә генә хәбәр сөйләп чыкты: көнбагышның бәясе 2 тапкыр арта, стаканы 2 мәртәбә кечерәя икән ди. Телсез кала яздым. Ярар, аның гына бәясе артмый калмас, черт с ним. Болай да күке төкерәге хәтле генә нәрсә сыя торган ул стакан кечерәйсә, аны тары ярмасы сатарга гына куярга була түгелме соң инде? Я оҗмахның зәм-зәм суын. Кара, вәт идея! Берсе ишетеп алса, чыгар да әле су сатарга. Яшәгәнебез оҗмах булгач, эчкәнебез зәм-зәм суы булуына бер дә гаҗәпләнәсе юк. Әллә бер 5 тәңкәсен булса да шунда калдырасымы? Хәер, тукта әле. Балалар кәчтүмнәре фәлән тәңкәдән 60 тәңкәгә арта дигәннәр. Пәлтә 170 тәңкә буласы дип язганнар. Анда каян алып акча кушасы икән соң? Әллә көнбагыш алмыйм микән? Юк, алам. Малайга кәчтүмне үзем тегәм. Үлчәгәнем бар: 44 размер мини итәктән кәчтүмнең арттактасы белән алтактасы чыга. Аны макси-итәк белән комбинировать итсәң, тулы кәчтүм һәм чалбарының бер балагы була яза. Чү, ә икенче балагы? Юк, шорты гына ясыйм. Хәер, нинди шорты ди—бу бит җылы кием. Черт с ним, тагы бер итәкне кушып, чалбарын да комбинировать итәргә инде. Шулай итеп, базар безне иллә дә мәгәр экономияле яшәргә өйрәтә: 3 итәктән бер балалар костюмын гөлт иттереп тегеп тә куясың. КияРлек булса, әлбәттә. И, кияРлек булмаса тагын, ахырдан барыбер сумка булса да җөйлисең. Алай гына эшләмәгән тегүчеләрме соң без?! Иң главное—компенсация янга кала. Тукта, ә үзеңә итәкне каян аласың? Әнә телевизордан күрсәттеләр: бер костюмитәк мең ярым чамасы торырга охшый. И, шулай булгач, ел ярымлык компенсация дә җитми була түгелме соң аңа? Шулай булгач, җәфаланып та тормыйм: компенсациянең 60 тәңкәсенә дә көнбагыш алам! Юк, юк, үгетләп тә маташмагыз, алам булгач алам. Принцип өчен алам. Аның политик, социаль ягы да ни тора. Базар экономикасына күчкәч, сез 1 мең—2 мең тәңкәлек күлмәк янында акчагызны капшап, күзләрегезне елтыратып торганда, мин әре генә перестройка чоры көнбагышын чиртеп, кабыгын сезнең күлмәк ягына төкереп, исем дә китмәгән кыяфәт белән үтәм дә китәм! Шулай итәм, алла боерса. Черт-черт! Сез алыгыз күлмәк! Черт-черт! Безгә көнбагыш та ярый! Черт-черт! Кем әйтә безне ярлы дип? Көнбагышның хакы ике тапкырга арткан, стаканы ике мәртәбә кечерәйгән була ич ул чакта! Черт-черт!

С. ХӘЙРУЛЛИНА.

Яшелчә бакчасына сый

Басуларга органик ашламалар чыгару эше январь, февраль айларында дәвам иткән иде инде. Мартта да эшне туктатканыбыз юк. Башка культуралар астына кертү белән яшелчә бакчасын да онытырга ярамый. Чөнки менә күп еллар инде колхозчыларыбыз үзебез кыяр, кишер, кәбестә, бәрәңге кебек яшелчәләрдән файдаланалар. Күбесе аның җәмәгать туклануына тотыла, ә кәбестә, кыяр кебекләрен шәхси хуҗалыкларга сатабыз.

Быел да яшелчә бакчасына ашлама чыгару өчен тракторчыларыбыз көч куя. Мифтах Фәссәхов җитәкчелегендәге бу бригадада Әсхәт Сафин төяп торучы, ә Хатыйп Даутов, Нәбиулла Мифтахетдинов, Рафик Митаков ташу эшендә. Шунысын да әйтик, биредә быел гына армиядән кайткан Фәнис Гыйләҗев та бар. Бу уңган егет солдатка киткәнче дә тракторда эшләгән иде һәм сынатмады. Әнә шундый яшьләрдә инде безнең ышаныч. Механизаторларыбыз исә көнлек нормаларын үтәп киләләр. Яшелчә бакчасы тиешле сый алыр диясе килә.

Н. ГАТАУЛЛИН.

Ульянов исемендәге колхоз.

Котлыйбыз!

Норлатта яшәүче кадерле әниебез Зөмәйрә Җамалетдин кызы Хәйруллинаны туган көне белән кайнар котлыйбыз. Аңа киләчәктә озын гомер, нык сәламәтлек, шатлык, бәхетле картлык телибез.

КЫЗЫ, КИЯВЕ, ОНЫГЫ.

Бар иде бит безнең дә яшь чаклар.

ҮТКЕН СҮЗЛӘР

КИТАП КИБЕТЕНДӘ

—Сездә «Ир—хатынга хуҗа» дигән китап бармы?

—Фантастика әнә теге бүлектә сатыла.

ФОКУС

Квалификация күтәрү курсларында укытучы берәүгә сорау бирә:

—Кара тактага линза сызып, шуның фокусы кайда булганын әйтегез.

—Мин, хөрмәтле укытучым, бирегә фокус күрсәтергә килмәдем.

НИШЛӘП УТЫРА?

Бер ханым авыл кибетенә керә дә сораша башлый:

—Чәй бармы?

—Юк, кайткан юк әле, —ди кибетче.

—Ә тоз?

—Тоз да юк.

—Бәлки сабын бардыр?

—Сабынга иртәгә барам...

—Бер нәрсәң дә булмагач, нишләп утырасың соң монда?

—Сезгә «юк» дип җавап бирер өчен утырам.

РЕСТОРАНДА

—Официант! Бу тавыкның бер аягы кыскарак бит.

—Сез аның белән биергә җыенмыйсыз ич...

БЕЛДЕРҮЛӘР

Республикада җәйге вакыт кертелмәү сәбәпле, гражданнарга йокыдан бер сәгатькә иртәрәк тору катгый тыела.

x x x

1 нче апрель «Көлү көне» булганлыктан, 2 апрель сыннар катканчы көлү көне дип игълан ителә. Элек көләсезме яки элек сыныгыз катамы—анысының әһәмияте юк.

x x x

Быел апрель шаярулары 1 нче апрельгә кадәр башкарылып бетә диярлек. Аның иң мәзәге—гражданнарга бирелә торган компенсация.

Көлегез, көлегез, файдасы күп, белегез...

СОРАУГА АҢЛАТМА

«Ветеран» кибетендә биек үкчәле туфлиләр саталар. 70 яшьлек картлар өчен шундый мода чыкканмы әллә хәзер?

БЕЗ КАЙДА ЯШИБЕЗ?

Норлатта яшәүче бер агай ерактан кунакка кайткан танышын очратты.

—Сез нинди республикада яшисез хәзер?—дип сорады кунак.

—ТССРда —диде горурланып якташыбыз.—Үткән елның 30 августыннан бирле без мөстәкыйль республика.

—Ышанмыйм,—диде кунак. —Шәһәрне урап чыгып та моны раслаучы дәлил тапмадым. Һәр предприятие, учреждение каршына «ТАССР» дип язылган вывескалар гына эленгән.

ЭМИГРАНТЛАР БУЛМАЯЧАК

Илгә керү, чыгу ирекe турында закон кабул ителгәнче үк кайбер предприятие һәм оешмалар җитәкчеләре саклык чаралары күрә башладылар. Кайда ничек, әмма РСУ төзүчеләренең берсе дә чит илгә чыгып китмәячәк. Читкә түгел үзебезнең илнең кирәк шәһәренә дә бара алмыйлар әле хәтта. Мәсәлән, Промышленная урамындагы кайбер йортларда яшәүчеләр елдан артык кулларына паспортларын тотып караганнары юк. Торак урынына теркәү өчен тапшыргач, теркәмиләр дә, бирмиләр дә. Ил эчендә йөрергә дә хокуклары булмаган ул төзүчеләргә чит ил паспорты төштә керсә генә инде.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШ

Колхозларда отчет җыелышына керсәң—сәгатьләр буена саннарны тыңлый-тыңлый изрәп китәсең. Аларны һич башка сөйләрып бетерү мөмкин түгел. Ул саннар һәр тармак буенча алдан махсус таблицага төшерелсә, халык игътибарына тәкъдим ителсә, кыйммәтле вакыт янга калыр иде. Бусы бер отыш. Икенчесе, колхозчылар нәтиҗәләрне алдан чагыштырып, фикерләрен туплап куяр, җыелыш та эчтәлекле һәм конкрет узар иде.

Т. АЛЯКИМОВА.

Түбән Норлат авылы.

Кәҗә белән базар

Тукайга ияреп

Безнең кәҗә бигрәк тату базар белән,
Менә базар карап тора тәрәзәдән
Кәҗә анда бәя күреп исе китә—
Автобуска утыра да ары китә.

Качмак була кәҗә базар хакларыннан—
Ни узмаган кәҗә бахыр башларыннан?
Әмма базар куа килә эзгә басып,
Котылам димә заман фетнәсеннән качып.

Сөйләштеләр, киңәштеләр, килештеләр
Һәм, ниһаять, уртак телгә ирештеләр:
Базар компенсациясен вәгъдә итә,
Кәҗә рәхмәт әйтә, сакалын селкетә.

Эт-кияү монологы

Минем әле ырлап торган
Гайрәтле һәм дәртле чак
Йөрәкләрдә дөрләп яна
Мәхәббәт дигән учак.

Сайладым Мыраубикәне
Характер түгел сәбәп.
Ярны сайлый белүе дә
Хәзер үзе бер сәләт.

Талонга көн күрим дисәң
Хәйлә белергә кирәк
Мыраубикә сөт суырса—
Үзем ялармын сөяк.

Характер берлеге түгел,
Тамак төрлеге хикмәт
Базар экономикасында
Шулай кирәк көн итмәк!

С. ХӘЙРУЛЛИНА.

АКЫЛЛЫ КЕШЕ

Хуҗа һәрвакыт үзалдына сөйләнеп йөри торган булган. Моңа гаҗәпләнеп бер кеше:

—Хуҗа әфәнде, нигә син гел үзалдыңа сөйләнеп йөрисең?— дигән.

—Гомер буе акыллы кешеләр белән сөйләшергә яраттым,—дигән Хуҗа.

ЙОКЫСЫ КАЧКАН

Хуҗа төн уртасында урамга чыгып ял итеп йөргәндә бер суфый очрап:

—Хуҗа, болай төн уртасында урамда ни эшләп йөрисең?—дип сораган.

—Йокым качкан иде, шуны эзләп йөрим,—дип җавап биргән хуҗа.

МАТУР БУЛЫР

Бер ханым фоторәсемгә төшәргә килә.

—Сез ничек тә тырышыгыз инде, рәсемем матур чыксын.

—Борчылмагыз, бик матур булыр,—ди фотограф, —хәтта үзегезне таный да алмассыз!

ТАБЫЛДЫКЛАР ӨСТӘЛЕ

Универмагның галантерея бүлегендә акча янчыгы табылды (акчасы да бар).
Сатучы Гафуровага мөрәҗәгать итегез.

Норлат-Октябрь автотранспорт предприятиесе «Д», «Е» категориясенә әзерләнү буенча курсларга шоферлар кабул итә.

x x x

Норлат-Октябрь АТПсына даими эшкә «Е» категорияле шоферлар, газ һәм электр белән эретеп ябыштыручылар, ДВС карбираторчы-мотористлары, бакырчы, автомашиналарның техник торышларын тикшерүче кирәк.

Белешмәләр өчен телефон: 2—10—90. АТПның кадрлар бүлеге.

МӨХӘРРИР **Ә. У. АБДУЛЛИН.**

Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы һәм КПССның район партия оешмасы.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары —2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны ФИДАНИЯ ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Асия МОРАТХАНОВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор— ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе. Күләме—1 басма табак. Заказ 37. Тираж 3.380.